ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
*БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ*
*БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ*

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
*БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН*
*БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ*

---

КАРАР
РЕШЕНИЕ

11 февраль 2021ел № 9-7

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 14 ноябрендәге 3-27 номерлы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Муниципаль берәмлекләр территорияләрен карауга санитар-эпидемиологик таләпләр турында» СанПиН 2.1.7.3550-19 санитар-эпидемиологик кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында» 2019 елның 5 декабрендәге 20 номерлы Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитария табибы карары нигезендә Буа шәһәр Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 14 ноябрендәге 3-27 номерлы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

104 пунктына түбәндәге эчтәлекле 104.5 пунктчасын өстәргә:

«104.5 Күмү(җирләү) урыннары территориясендә агачлар һәм куаклар утырту рөхсәт ителми.».

2. Буа шәһәр Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар проектын хупларга.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча басылып чыккан көненнән закон көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа шәһәре Башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов